БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
18 гыйнвар 2022 ел

**КАРАР**
№ 104

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнец вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясенец бердәм составын раслау турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре белән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 103 номерлы карар нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. 2013 елның 19 декабрендәге 199 номерлы карар (2018 елның 1 ноябрендәге 150 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнарында конкурс тиешле органда муниципаль хезмәтнең вакантлы (муниципаль хезмәткәр биләмәгән) вазыйфасы булганда, Балтач муниципаль районы башлыгының хокукый акты белән игълан ителә.»;

1.2. Нигезләмәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 Татарстан Республикасы Балтач район Советының кадрлар һәм җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында «Кадрлар сәясәте» бүлегендә, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, Балтач муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларында түбәндәге мәгълүматларны урнаштыруны гамәлгә ашыра:

- конкурс үткәрү һәм аны үткәрү шартлары турында белдерү;
- конкурсның икенче этабы һәм конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат.»;

1.3. Нигезләмәнең18 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләр керә: Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Балтач район Советының кадрлар һәм җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге хезмәткәрләре, юридик бүлек хезмәткәрләре, аңа карата конкурс билгеләнгән вакантлы вазыйфа булган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирлек башлыгы), Балтач муниципаль районы Иҗтимагый Советы рәисе һәм бәйсез экспертлар.

Конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары белән раслана»;

1.4. Нигезләмәнең 19 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре конкурс комиссиясе утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә, конкурс комиссиясе әгъзаларына утырыш чакырылу турында хәбәр итә, комиссия әгъзаларына көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, гаризалар, документлар кабул итә һәм терки, гражданнарның документларын тикшерә, аларга конкурсның икенче этабы турында хәбәр итә, конкурс комиссиясе карарлары проектларын әзерли, конкурс комиссиясе рәисе кушуы буенча башка функцияләрне үти, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия утырышын үткәрү кысаларында оештыру-техник чаралар, Бердәм конкурс комиссиясе карарын билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерә, конкурста катнашучыларга конкурс нәтиҗәләре турында хәбәр итә, Бердәм конкурс комиссиясе эше нәтиҗәләре буенча мәгълүматны Җирле үзидарә органына (Җирлеккә) җибәрә (рәсми хат, комиссия беркетмәсе).»

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясенең бердәм составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2022 елның «18» гыйнварындагы
104 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясенең бердәм составы**

| | |
|---|---|
| Сабирҗанов Н.Н. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Мөхәммәтҗанова Р.Х. | Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесе, рәис урынбасары; |
| Мөхәммәтшина А.И. | Татарстан Республикасы Балтач район Советының кадрлар һәм җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы, комиссиянең җаваплы секретаре; |
| Фатыхов Р.С. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; |
| Таҗетдинов Р.А. | Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе; |
| | аңа карата конкурс билгеләнгән вакантлы вазыйфа булган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирлек башлыгы); |
| | бәйсез экспертлар. |